| | | |
|---|---|---|
| **РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН** | | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ** |
| **ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ТЮЛЯЧИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА** | | **ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ** |

---

| | | |
|---|---|---|
| **ПОСТАНОВЛЕНИЕ** | **с. Тюлячи** | **КАРАР** |
| «23» апреля **2026 ел** | | **№ 53** |

Теләче муниципаль районы территориясеннән Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган Россия Федерациясе гражданнары балаларына күрсәтелә торган социаль ярдәм чаралары турында

Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгының 2026 елның 18 мартындагы 01-20/2101 номерлы хатын карап, Теләче муниципаль районы территориясеннән Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган Россия Федерациясе гражданнары балаларына социаль ярдәм күрсәтү максатларында, Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясендә өлешчә мобилизация игълан итү турында» 2022 елның 21 сентябрендәге 647 номерлы Указы нигезендә, Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Теләче муниципаль районы территориясеннән Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган Россия Федерациясе гражданнары балаларына күрсәтелә торган социаль ярдәм чаралары буларак, аларга Төләче муниципаль районы җирле пассажир транспортында исемле электрон юл (проездной) билетлары (транспорт картасы) (алга таба - электрон юл билеты) ярдәмендә бушлай йөрү хакы бирү.

2. Электрон юл билеты, ата-аналарының берсе Теләче муниципаль районы территориясеннән Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизацияләү буенча хәрби хезмәткә чакырылган Россия Федерациясе гражданины булган 8 яшьтән 18 яшькә кадәрге (шул яшьне дә кертеп) балаларга Теләче муниципаль районының барлык төрдәге пассажир транспортында йөрү хокукын бирә.

Электрон юл билеты шәһарара автобус маршрутларына кулланылмый.

Электрон юл билеты Теләче муниципаль районы җирле пассажир транспортында йөрүне карта белән түләү операцияләрен башкару өчен, пассажир транспортында йөрүне түләүнең автоматлаштырылган системасын кулланып, җәмгыяви кулланыштагы пассажир транспортында түләүсез йөрү өчен билгеләнгән.

3. Электрон проездной билет Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган Теләче муниципаль районы

территориясеннән булган Россия Федерациясе гражданнары белән туганлыкны раслаучы документлар нигезендә бирелә:

- 18 яше тулмаган балалар өчен – ата-аналарның (законлы вәкилләрнең) гаризасы буенча;

- 18 яше тулган балалар өчен – үзләренең шәхси гаризалары буенча.

4. Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты Инфраструктура үсеше бүлегенә түбәндәгеләрне тәэмин итергә:

4.1. Теләче муниципаль районы территориясеннән Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган Россия Федерациясе гражданнары балалары өчен электрон юл йөрү билетлары әзерләү;

4.2. Теләче муниципаль районы территориясеннән Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган Россия Федерациясе гражданнарының балаларына Теләче муниципаль районы пассажир транспортының барлык төрләрендә электрон юл йөрү билетлары буенча бушлай йөрү мөмкинлеге бирү.

5. МКУ "Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты Мәгариф бүлеге"нә буйсынган гомуми белем бирү учреждениеләре аша тәэмин итергә:

5.1. әлеге карарның кушымтасы нигезендә электрон юл билетлары бирүгә гаризалар кабул итүне;

5.2. Теләче муниципаль районы территориясеннән Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган Россия Федерациясе гражданнары балалары өчен электрон юл йөрү билетлары тапшыру.

6. Социаль ярдәм чараларын күрсәтүне финанс белән тәэмин итү әлеге карар нигезендә Теләче муниципаль районы бюджеты акчалары исәбеннән гамәлгә ашырыла.

7. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүматы порталында түбәндәге адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru һәм Теләче муниципаль районының рәсми сайтында: http://tulachi.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

Җитәкче И.Х. Хәмидуллин

Татарстан Республикасы
Теләче муниципаль районы
Башкарма комитетының
«23» 04 2026 № 53
карарына кушымта

(форма)

Директорга
______________________________
Татарстан Республикасы
Теләче муниципаль районы мәктәбе
кемнән: ______________________
______________________________,
(ата-ананың (законлы вәкиленең)/18 яше тулган баланың ФИАИ)
түбәндәге адреста яшәүче:
______________________________

Гариза

Сездән ______________________ электрон юл билетын бирүегезне сорыйм
_____________________________________________,
(Теләче муниципаль районы территориясеннән РФ Хәрби Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган РФ гражданины баласының ФИАИ)

______________ ______________________________
(улы/кызы/тәрбияләнүче (Теләче муниципаль районы территориясеннән РФ Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган РФ гражданины ФИО)

_____________________________________________

Кушымта: _____________________________________
_____________________________________________
(Теләче муниципаль районы территориясеннән РФ Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган РФ гражданы белән туганлыгын раслаучы туу турында таныклык күчермәсе)

Имза ______________________ ____________________
(имзаның аңлатмасы)

Дата «___» ___________ 20__ел